ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.04.2021 Олы Кайбыч ав. № 150

Социаль наем шартнамәсе буенча торак урын мәйданының хисап нормасы һәм торак урын мәйданын бирү нормасы турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 50, 58 статьяларын гамәлгә ашыру, дәүләт торак программаларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставының 45 статьясы нигезендәТатарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында гражданнарны торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында тәэмин ителеш дәрәҗәсе билгеләнә торган торак урын мәйданының хисап нормасын гаиләнең бер әгъзасына торак урынның гомуми мәйданы 18 кв. метрдан кимрәк дип билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннар белән тәэмин ителешнең ирешелгән дәрәҗәсеннән чыгып, бер гражданга торак урынның гомуми мәйданының 18 кв. метр күләмендә торак урын бирү нормасын билгеләргә.
3. Торак урынның гомуми мәйданын бирү нормасын арттыру Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда рөхсәт ителә.
4. «Социаль наем һәм дәүләт торак программалары буенча гражданнарга торак бирү һәм исәпкә куйганда торак мәйданы нормалары турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2006 елның 17 ноябрендәге 313 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
5. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырып чыгарырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары Ф.Ш.Әхмәтовка йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров